**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица М.Титова, дом 7, Черемшан село, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс 8(84396)2-52-30  email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

**03 апрель 2026 ел** **№ 18**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 16 ноябрендәге №9 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге № 425-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 16 ноябрендәге 9 номерлы карарына (Советның 2023 елның 13 ноябрендәге 101 номерлы, 2024 елның 08 ноябрендәге 128 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 136 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2) Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр - оешмалар өчен салым органнары агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталлары тәмамланганнан соң салым буенча аванс түләүләре суммаларын җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бер өлеше буларак исәплиләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Л.С.Гатина